**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Аларга билгеләп кую һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан башкарыла торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен һәм башка аерымлык билгеләрен кабул итүе тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында**

Аларга билгеләп кую һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан башкарыла торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен һәм башка аерымлык билгеләрен кабул итү мөмкинлеге күздә тотылган Россия Федерациясе законнары нормаларын гамәлгә куюны тәэмин итү максатларында **карар бирәм**:

1. Аларга билгеләп кую һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан башкарыла торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен һәм башка аерымлык билгеләрен кабул итү тәртибе турында кушымтада бирелүче нигезләмәне расларга.

2. Аларга билгеләп кую һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан башкарыла торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның фән һәм спорт өлкәсендәге исемнәрен (бүләкләрен) алырга рөхсәт ителә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт органнарына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең, шул исәптән дини берләшмәләрнең, һәм башка

Татарстан Республикасы
Президентының
2016 елның « 12 » гыйнварындагы
ПУ- 5 номерлы Указы белән
расланды

**Аларга билгеләп кую һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан башкарыла торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен һәм башка аерымлык билгеләрен кабул итүе тәртибе турында**
**нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмәдә аларга билгеләп кую һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан башкарыла торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен һәм башка аерымлык билгеләрен (фән һәм спорт өлкәсендәгеләреннән тыш) (алга таба – исемнәр, бүләкләр) кабул итү тәртибе билгеләнә.

2. Аларга билгеләп кую һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан башкарыла торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар (алга таба – вазыйфаи зат) мактаулы исемнәр, бүләкләр алганда Татарстан Республикасы Президентының рөхсәтен алырга тиеш.

3. Мактаулы исем, бүләк алган яисә мактаулы исемне, бүләкне алачагы турында чит дәүләт, халыкара оешма, сәяси партия, бүтән иҗтимагый берләшмә һәм башка оешмадан хәбәрнамә алган вазыйфаи зат өч эш көне дәвамында Татарстан Республикасы Президентына, чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең яки башка оешманың мактаулы исемен яки махсус дәрәҗәсен, бүләген һәм башка аерым билгесен кабул итеп алырга рөхсәт бирүен сорап, 1 нче кушымтадагы форма буенча тутырылган үтенеч язуы (алга таба - үтенеч язуы) тапшыра.

4. Мактаулы исемнән, бүләктән баш тарткан вазыйфаи зат өч эш көне дәвамында Татарстан Республикасы Президентына чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең яки башка оешманың мактаулы исемен яки махсус дәрәҗәсен, бүләген һәм башка аерымлык билгесен кабул итеп алудан баш тартуы турында 2 нче кушымтагы форма буенча тутырылган хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) тапшыра.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзалары Татарстан Республикасы Президентына үтенеч язуы яки хәбәрнамә тапшыру белән берррәттән, бу турыда Татарстан Республикасы Премьер-министрына да мәгълүмат бирә.

6. Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан үтенеч язуын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кабул ителгәнче мактаулы исем, бүләк алган вазыйфаи зат мактаулы исем документларының төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа документларның төп нөсхәләрен аларны кабул итеп алганнан соң өч эш көне дәвамында Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының аларны саклау өчен җаваплылык йөкләтелгән дәүләт бүләкләре бүлегенә тапшыра.

7. Әгәр хезмәт командировкасы вакытында вазыйфаи зат мактаулы исем, бүләк алса яисә алардан баш тартса, үтенеч язуы бирү вакыты вазыйфаи затның хезмәт командировкасыннан кайткан көненнән алып санала.

8. Вазыйфаи зат үтенеч язуын яисә хәбәрнамәне, мактаулы исем документларының төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның документларының төп нөсхәләрен аннан тормый торган сәбәпләр аркасында әлеге Нигезләмәнең 3, 4 һәм 6 пунктларында күрсәтелгән вакытта тапшыра алмый икән, әлеге вазыйфаи зат үтенеч язуын яисә хәбәрнамәне, мактаулы исем документларының төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның документларының төп нөсхәләрен сәбәп бетерелгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырырга тиеш.

9. Татарстан Республикасы Президентының үтенеч язуын каравын тәэмин итүне, Татарстан Республикасы Президентына үтенеч кәгазе тапшырган (юллаган) затка Татарстан Республикасы Президентының үтенеч кәгазен карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карары турында хәбәр итүне, шулай ук үтенеч кәгазьләре исәбен алып баруны, Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының дәүләт бүләкләре бүлеге Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе билгеләгән тәртиптә тормышка ашыра.

10. Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаи затның әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән үтенеч язуын канәгатьләндергән очракта, Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының дәүләт бүләкләре бүлеге 10 эш көне дәвамында әлеге вазыйфаи затка мактаулы исем документларының төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның документларының төп нөсхәләрен тапшыра.

11. Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаи затның әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән үтенеч язуын канәгатьләндерүдән баш тарткан очракта, Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының дәүләт бүләкләре бүлеге 10 эш көне дәвамында әлеге вазыйфаи затка бу хакта хәбәр итә һәм мактаулы исем документларының төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның документларының төп нөсхәләрен чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең яки башка оешманың тиешле органына юллый.

12. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзасының үтенеч язуын карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Президенты карары турында Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының дәүләт бүләкләре бүлеге Татарстан Республикасы Премьер-министрына 10 эш көне дәвамында хәбәр итә.

Аларга билгеләп кую һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан башкарыла торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен һәм башка аерымлык билгеләрен кабул итүе тәртибе турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Президентына

_______________________________________________

_______________________________________________
(Ф.И.А.и., биләгән вазыйфа)

## Чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең яки башка оешманың мактаулы исемен яисә махсус дәрәҗәсен, бүләген яисә аерымлык билгесен кабул итеп алырга рөхсәт турында үтенеч язуы

___________________________________________________________________________
(мактаулы исем яисә махсус дәрәҗәнең, бүләк яисә башка батырлык билгесенең атамасы)

___________________________________________________________________________
(нинди хезмәтләр өчен кем тарафыннан бирелгән исем, нинди хезмәтләре өчен кем тарафыннан бүләкләнгән)

___________________________________________________________________________
(мактаулы исемгә яисә махсус дәрәҗәгә документлар, бүләк яисә аерымлык билгесе

_______________________________кабул итеп алырга рөхсәт итүегезне үтенәм.
тапшыру вакыты һәм урыны)

Мактаулы исемнең яисә махсус дәрәҗәнең, бүләкнең яисә башка аерымлык билгесенең документлары (тиешлесенең астына сызарга)

___________________________________________________________________________
(мактаулы исем яисә махсус дәрәҗәнең, бүләк яисә башка аерымлык билгесе атамасы)

___________________________________________________________________________
(мактаулы исем яисә махсус дәрәҗәнең,

___________________________________________________________________________
бүләк яисә башка аерымлык билгесенең документлары атамасы)

__________ номерлы тапшыру-кабул итү акты буенча 20_____ елның «____» ______________ Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының дәүләт бүләкләре бүлегенә тапшырылды.

20____ елның «____»______________ ___________________ ________________
(имза) (имзаны шәрехләү)

_________

Аларга билгеләп кую һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан башкарыла торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен һәм башка аерымлык билгеләрен кабул итүе тәртибе турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Президентына
___________________________________________
___________________________________________
(Ф.И.А.и., биләгән вазыйфа)

Чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең яки башка оешманың мактаулы исемен яисә махсус дәрәҗәсен, бүләген яисә башка аерымлык билгесен кабул итеп алудан баш тарту турында хәбәрнамә

______________________________________________________________________
(мактаулы исем яисә махсус дәрәҗәнең, бүләк яисә башка батырлык билгесенең атамасы)
______________________________________________________________________
(нинди казанышлар өчен кем тарафыннан тапшырылган, нинди казанышлар өчен кем бүләкләгән)

_____________кабул итеп алудан баш тартырга карар кылуым турында хәбәр итәм.

20___ елның «____»___________ ______________ ___________________
(имза) (имзаны шәрехләү)

________

оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен (гыйльми дәрәҗәләрдән тыш), бүләкләрен кабул итү тәртибен раслауны тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Премьер-министры чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен һәм башка аерымлык билгеләрен аларга билгеләп кую һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан башкарыла торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар өчен каралган тәртиптә башкарыла дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына аларга сайлау яки билгеләү Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан башкарыла торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен һәм башка аерымлык билгеләрен кабул итү тәртибен билгеләргә тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә аларга сайлау Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан башкарыла торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен һәм башка аерымлык билгеләрен кабул итү тәртибен билгеләргә тәкъдим итәргә.

7. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 ел., 12 гыйнвар
№ ПУ-5